МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.09.2020 г.Казань № 609

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 5 октяберендә 6873 номеры белән теркәлде

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы «Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» боерыгы белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1.Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 7 июнендәге 317 номерлы, 2016 елның 31 октябрендәге 612 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге 349 номерлы, 2018 елның 1 июнендәге, 426 номерлы, 2018 елның 18 сентябрендәге 860 номерлы, 2019 елның 23 апрелендәге 297 номерлы, 2019 елның 14 ноябрендәге 1021 номерлы, 2020 елның 10 февралендәге 84 номерлы, 2020 елның 8 июнендәге 400 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) (алга тада - Үзгәрешләр)расланган торак

урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык беләнкертелгән үзгәрешләр 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә торган бишенче - егерме дүртенче үзгәрешләр моңа керми.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 04.09.2020 ел.
№ 609 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы белән расланган торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.5 пункттагы «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2.6 пункттагы «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы унберенче абзац

«торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр турында, соңгы 3 елдан да артмаган вакыт эчендә (вәкаләтле органнарда) барлыкка килгән торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләнмәгән бурычның законлы көченә кергән суд акты тарафыннан расланган булуы (булмавы) турында;»;

2.14 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.5.2 пунктының 1 пунктчасында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла.

Инвалидларга законнар чыгару һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә объектлардан файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән хезмәт күрсәтүче

объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозылган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән хезмәтләрне алу өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-нокталы шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын  раслый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2015 елның 21 июлендә теркәлгән, теркәү номеры 38115) белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, хезмәт күрсәтүләр башкарыла торган объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Инвалидларга закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә хезмәтләрдән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга хезмәт күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән хезмәт алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, хезмет күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып хезмәт күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене кертелүне тәэмин итү;

в) хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче орган һәм оешма хезмәткәрләренең инвалидларга башка затлар белән тигез хезмәтләр алуга комачаулаган киртәләрне үтәргә ярдәм итүе;

г) хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-нокталы Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук теркәү бүлегендә аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.»;

«Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон; Россия Хезмәт министрлыгының «Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә инвалидларның файдалана алуы һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану шартларын тәэмин итү тәртибен раслау, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» 2015 елның 30 июлендәге 527н номерлы боерыгы;

3 бүлектә:

3.3.2.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүләр турында, законлы көченә кергән суд акты тарафыннанән расланган, вәкаләтле органнардан соңгы 3 елдан да артмаган вакыт эчендә җыелган торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләнмәгән бурыч булу (булмау) турында»;

3.4.2.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүләр турында, законлы көченә кергән суд акты тарафыннанән расланган, вәкаләтле органнардан соңгы 3 елдан да артмаган вакыт эчендә җыелган торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләнмәгән бурыч булу (булмау) турында»;